# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Иске Имән авыл җирлегенең Иске Имән авылы торак пунктында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**18.11.2022 ел** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 18 ноябрендә 09.00 сәгатьтә үткәрелгән «2023 елда 500 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Имән авыл җирлеге территориясендә Иске Имән авылында I төркем инвалидлардан; контракт буенча хәрби хезмәт, мобилизация буенча хәрби хезмәт, ашыгыч хәрби хезмәт үтүче гражданнардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде:

1. Иске Имән авыл клубы территориясен коймалау өчен төзелеш материаллары сатып алу;
2. Иске Имән торак пункты зиратында хуҗалык йорты төзү өчен төзелеш материаллары сатып алу;
3.Иске Имән торак пункты урамнарын яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, агымдагы ремонт һәм урамнарны яктырту);
4. Иске Имән торак пунктында кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
5. Иске Имән торак пунктында җәйге вакытта территорияне һәм юл буе полосаларын чабу (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
6. Иске Имән торак пунктында көнкүреш калдыклары һәм чүп-чар җыю урыннарын җыештыру;
7. Иске Имән торак пунктында Бөек Җиңү көне, Өлкәннәр көне, Инвалидлар көне, Яңа ел, Сабантуй бәйрәмнәрен үткәрү өчен бүләкләр алу.

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 151 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 110 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында «РИЗА» позициясе өчен 110 катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен  0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районының Иске Имән авыл жирлегенең Иске Имән авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип таныргa, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип таныргa.

2. «2023 елда 500 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Имән авыл җирлеге  территориясендә Иске Имән авылында I төркем инвалидлардан; контракт буенча хәрби хезмәт, мобилизация буенча хәрби хезмәт, ашыгыч хәрби хезмәт үтүче гражданнардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән,  җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме» дигән сорау буенча карар кабул итәргә:

1. Иске Имән авыл клубы территориясен коймалау өчен төзелеш материаллары сатып алу;

2. Иске Имән торак пункты зиратында хуҗалык йорты төзү өчен төзелеш материаллары сатып алу;

3.Иске Имән торак пункты урамнарын яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, агымдагы ремонт һәм урамнарны яктырту);

4. Иске Имән торак пунктында кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

5. Иске Имән торак пунктында җәйге вакытта территорияне һәм юл буе полосаларын чабу (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

6. Иске Имән торак пунктында көнкүреш калдыклары һәм чүп-чар җыю урыннарын җыештыру;

7. Иске Имән торак пунктында Бөек Җиңү көне, Өлкәннәр көне, Инвалидлар көне, Яңа ел, Сабантуй  бәйрәмнәрен үткәрү өчен бүләкләр алу.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Иске Имән авыл җирлегенең мәгълүмати стендларына  урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Имән авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Сарман муниципаль районы
Иске Имән авыл җирлеге башлыгы,
халык җыенында рәислек итүче Р.Ә.Исламова